УДК 821.512.145

***Ч.Ф. Ситдыйкова***

# XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ПРОЗАСЫ ПОЭТИКАСЫ (Ф. Сафинның 1985–2005 еллар иҗаты мисалында)

Ф. Сафин является одним из ярких представителей татарской прозы конца XX – начала XXI века. В статье рассматриваются произведения автора, написанные в 1985–2005 годах с точки зрения поэтики, в частности анализируются поэтические приемы изображения действительности. Особое внимание при этом уделяется рецензиям, критическим статьям, воспоминаниям о произведениях данного периода.

**Ключевые слова:** татарская проза, Ф. Сафин, поэтические приемы.

F. Safin is one of the most remarkable representatives of Tatar prose of the late XX – early XXI century. The article examines the works of this author, written in 1985–2005 from the point of view of poetics; in particular, analyzes the poetic techniques of depicting reality. Special attention is paid to reviews, critical articles and memoirs of the works of this period.

**Keywords:** Tatar prose, F. Safin, poetic techniques.

XX гасыр азагы – XXI гасыр башы татар прозасының күренекле вәкиле Ф. Сафинның беренче күләмле әсәре – «Соңгы көз» повесте 1987 – 1988 елларда иҗат ителә, 1990 елны «Таң йолдызы» газетасында басыла, 1992 елда аерым китап булып дөнья күрә. Совет кешесендәге борынгыдан сакланган әхлак кануннарына туры килмәгән сыйфатларны, заман каршылыкларын кыю актырткан әсәр җәмәгатьчелектә резонанс тудыра: ул кулдан-кулга күчеп укыла, аның язылу-басылу факты язучының шәхси кыюлыгы дип бәяләнә.

«Соңгы көз» әсәрендә тоталитаризмның кеше шәхесенә йогынтысы үзәк герой – колхоз рәисе Тимерхан Заманов образы аша күрсәтелә. Әлеге образны тудыруда әдип ретроспекция алымын куллана: совет чоры вәкилен укучы күз алдына бөтен тулылыгы белән бастыра. Заманов – үз районында иң кодрәтле кешеләрнең берсе: партия өлкә комитеты әгъзасы, РСФСР Югары Советы депутаты. Аның «тырышлыгы» белән колхоз алдынгылар рәтендә бара. Ф. Сафин Замановны тарихи шәхес, совет дәүләте белән бәйләнгән кеше, заманның тимердәй ханы булырга дәгъва итүче кебек сурәтли [Заһидуллина, 2006, б. 56]. Язучы аңлы рәвештә совет чоры әсәрләрендәге сюжетка, мотивка, образларга мөрәҗәгать итеп (аллюзия), аны үзенчә үзгәртә, үткәндәге хәлләргә интерпретация ясый, укучыга совет чорына, шәхесләргә башка яктан карарга мөмкинлек бирә.

Заманов үзен авыл халкыннан өстен, тиңдәшсез хуҗа, бердәнбер хөкемдар итеп тоя, ул – кырыс, кансыз, калган кешеләр – аңа буйсынучылар, ягъни коллар, шәүләләр. Тимерхан үзенә каршы

килүчеләрне «юк итә». Үз фикерләрен белдерергә курыкмаган бердәнбер кеше – мәктәп директоры Камил Сабировны, яла ягып, эштән кудыруы – моның ачык мисалы. Бу геройның исеме дә символик эчтәлекле: бар яктан камил, үрнәк, кешелекле, дөреслек өчен көрәшүче шәхеснең үзенә тәңгәл.

Әсәрдәге төп конфликт – Заманов һәм аның тирәсендәгеләр (хуҗа-кол) каршылыгы буларак гәүдәләнә. Кол бернинди дә хокукка ия түгел, ул хуҗасына карусыз буйсынырга, боерганнарны үтәргә тиеш. Язучы геройларны капма-каршы куеп, төп игътибарны берәүләрнең – рәхимсез рәвештә изүче, җәберләүче, башкаларга карата физик көч кулланырга омтылучы булуына; икенчеләрнең – алда әйтелгәннәре алдында көчсезләнүе, куркуы, карусыз буйсынуы, үз иминлеге, тынычлыгы өчен көрәшмәвенең сәбәпләренә юнәлдерә. Совет чоры авылы кешеләре һәртөрле мөстәкыйль эшчәнлектән, irekле гамәлләрдән, сүз ирегеннән мәхрүм. Кеше һәм социалистик җәмгыять берлеге, берәүгә дә аңа каршы чыгарга ярамаганлык, гомумән, кешенең әлеге җәмгыятьтән башка «яши алмавы» совет чоры авылы адәмнәренең уйларына, фикерләү үзенчәлегенә кадәр үтеп кергән. Авыл тулаем совет җәмгыяте моделе кебек тасвирлана. Совет авылы кешеләренең трагик язмышы, җитәкчеләр алдында көчсезлеге беренче планга чыга. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәте курку, «өстәгеләргә» ярарга тырышу белән чикләнә. Авыл-ил – язучының иҗтимагый стройдан, социалистик системадан ирония белән һәм яшь аралаш көлү урыны.

Әсәр ахырында рәиснең фаҗигалы үлеменә символик мәгънә салынган. Моның белән язучы тулаем системаның да соңгы көзенә якынлашуын искәртә. Табигатькә мөрәҗәгать итү әсәр ахырында хуҗа-кол каршылыгына үзгә шәрехләү, аңлатма китереп чыгара. Табигатькә көз хуҗа булган кебек, җәмгыятьтә дә берәү дә, хәтта үзен хуҗа дип санап йөргән кешеләр дә, тарихи барыштан читтә калып, аның кыравыннан саклана алмый. Барысы да – коллар, башкаларга кол итеп караган «хуҗа»лар да, ахыр чиктә, системаның вак уенчылары булып чыга. Заманов – советчыл система корбаныннан системаның тугры вәкиленә, тирәнрәк уйлаганда, шул система колына әверелгән кеше. М. Әгъләм аны «фаҗигаларның сәбәпчесе һәм корбаны» [Әгъләмов, 1993] дип атый. Әсәрнең үзәгенә мондый геройны кую әлеге еллардагы иҗтимагый атмосфераны тергезергә, системаның нигезенә салынган идеяләрнең дөрес булмавын, халык өчен эшләмәвен, илдәге торгынлык-кризисның шуның нәтиҗәсе булуын ачарга ярдәм итә. Әсәрнең башындагы табигать сурәте исә совет дәверен гомумән көз белән тәңгәлләштерә: *«Бар дөнья томанлы эңгергә чумган. Урам як бакчада үскән миләшләр ботаклары белән тәрәзәгә кагылып-чиртеп алалар. Кыраулы суыкта күшеккән миләшләр табигатьнең рәхимсезлегенә зарланалар сыман. Җимешләр ут яна, тамырларга суык үрмәли. Көз, көз... Табигатьтә көз хакимлек итә»* [Сафин, 1992, б. 4].

Ф. Сафинның «Гөлҗиһан» (1994) повестенда әлеге тема үзенчәлекле дәвам иттерелә. Үзәк герой Гөлҗиһанның тормыш юлы халык язмышына бәйле тергезелә: ятимлек, атасы һәм үги ана хакына яратмаган кешегә кияүгә чыгу, ир хыянәте, авыр физик хезмәт, баласының гарипләнүе, онык үстерү мәшәкатьләре һ.б. Героиняның яшьлеген тасвирлаганда ук, язучы хакимиятнең үзгәреш эволюциясен һәм совет җәмгыятендә кешегә мөнәсәбәтне күрсәтә. Кызның этисе Фәрвәй Мөлеков – 1930 – 1940 еллар совет системасы тәрбияләгән җитәкче тибы, колхоз рәисе; кырыс, үзсүзле, каты бәгырьле, мәрхәмәтсез кеше. Балаларының язмышын хәл иткәндә, ул үзенең шәхси мәнфәгатьләреннән чыгып эш итә. Фәрвәйнең максаты – кызын Гыйльметдиннән аеру һәм тормышын, аның исәбенчә, «үзенә тиң кеше белән бәйләү». Әлеге мәсьәлә, тирәнрәк уйлаганда, социаль якка килеп тоташа. Улы Шәйхаттар да, Фәрвәйнең әниләре үлемендә сәбәпче булган хатынга өйләнүен кабул итә алмыйча, каравыл өендә яшәргә мәҗбүр. Гөлҗиһан белән Шәйхаттар Фәрвәйнең сүзеннән чыга алмаган кебек, халык та система кулында уенчык булуга ишарә ясала.

Төп герой Гөлҗиһан – көчле рухлы, җаваплылыкны үз җилкәсенә алырга курыкмый торган хатын-кыз. Ул татар әдәбияты өчен традицион (Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» (1965), Ф. Хөснинең «Гыйльмениса» (1968), Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» (1976), А. Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» (1980) һ.б. әсәрләр), авторның идеалы буларак бирелә.

Язучы Гөлҗиһан образына бәйле рәвештә ислам диненә, гореф-гадәтләргә мөрәҗәгать итә. Иң кыен минутларында да, иң бәхетле мизгелләрендә дә Гөлҗиһан Ходайга ялвара. Дини ышанулары геройга тормыш авырлыкларын җиңәргә булыша, күңелен тынычландыра. Әсәрдә Алла, Ходай, дога сүзләре еш кулланыла, никах укыту, яшь баланы алып кайткач, теләкләр теләү, исем куштыру, Сабантуй бәйрәме, боз китү күренешләре тасвирлана. Ф. Сафин халыкның төп халәтен хезмәт куеп яшәүдә күрә, аның алдынгы традицияләре – әхлакый сафлыгы, сабырлыгы, матурлык идеаллары – барысы да хезмәт даирәсенә урнашкан булуын раслый, кешелек бәхетенең хезмәткә бәйле булуын аңлата.

Гөлҗиһанга хас кызгану хисе әсәрдә зур әһәмияткә ия. Сюжетта каршылык оешу ноктасы – Гөлҗиһанның үзе теләмәгән кешегә кияүгә чыгуы ук шушы сыйфатка барып тоташа. Геройның кызгана белү сәләте абыйсы Шәйхаттарга мөнәсәбәтендә дә ачык күренә. Шәйхаттар образы милли проблеманы, төгәлрәк әйткәндә, катнаш никахлар, туган җирдән читтә яшәүне яктыртуда төп вазифаны башкара. Армиядән соң ул туган авылына кайтмый, акча эшләү максаты белән, Урта Азиягә китә. Иң авыр минутларында сеңлесенә терәк булырга аның вакыты да, ихтыяр көче дә җитми. Үз милләтеннән булмаган кызга өйләнеп, картлык көннәрендә сеңлесе өенә кайтып егылуы – Шәйхаттар фаҗигасы гына түгел, халык фаҗигасы да. Автор әйтергә

теләгән төп фикер Гөлҗиһан тарафыннан ишеттерелә: *«Их, үзебезнең татар кешесенә өйләнгән булса!»,* аның сүзләре автор фикере белән тәңгәлләшә. Гөлҗиһан сөйләме аша язучы заманга үз бәясен бирә, диненнән, туган җиреннән аерылган кешенең язмышы аянычлы булуын ассызыклый.

Шулай итеп, Гөлҗиһанның гаять катлаулы тормыш юлын сурәтләү белән бергә, әсәрдә образга киң иҗтимагый-фәлсәфи яңгыраш салына, ул халык, милләт язмышын бәяләүгә хезмәт итә башлый.

«Саташып аткан таң» (1999 – 2003) роман-трилогиясенең нигезендә татар халкының тормышында мөһим урын алып торган совет чоры, якынча 1917 – 1938 елларда булып узган сәяси вакыйгалар ята. Ун елга сузылган эзләнүләре дәвамында Оренбург, Казан, Уфа, Мәскәү һ.б. шәһәрләрдәге төрле дәүләт архивларында тупланган тарихи документларны, фәнни әдәбиятны һ.б. чыганакларны өйрәнеп, фактик материалларга, үзәк геройның улы Марат Дәүләтъяров истәлекләренә нигезләнеп, Ф. Сафин татар халкының Ә. Дәүләтъяров, Ш. Усманов, М. Җәлил, Ш. Камал, С. Сәйдәшев кебек тарихи шәхесләренең фаҗигалы язмышын яктырта.

Роман өч китаптан тора: «Сакмар егете», «Өермә», «Ялган тәрәзәле йорт». Әсәрдә революция, гражданнар сугышы, колхозлашу, репрессия кебек күренешләр тирән анализлана, совет чорындагы иҗтимагый тормышның эчке закончалыгы, җанлы хәрәкәте сәнгатьчә ачып бирелә, чорның типлары, характерлары заман таләп иткән югарылыкта күрсәтелә [Хөснетдинова, 2004, б. 22]. Әсәрнең башында ук метафора бирелү революциягә, большевизмга гомуми бәя кебек яңгырый, романны аңлауга ачкыч булып тора: таң ике тапкыр ата.

Трилогиянең беренче китабы («Сакмар егете») үзәк герой Әхмәтсафа Дәүләтъяровның 1917 – 1929 еллардагы тормышын, белем алу елларын үз эченә ала, геройга бәйле рәвештә революция, гражданнар сугышы, ачлык кебек күренешләргә, советчыл тәрбия-әхлак мәсьәләләренә киң тукталына. Әлеге күренешләр совет чоры әдәбиятында да чагылыш тапты (К. Нәҗминең «Язгы җилләр» (1948), И. Газинең «Онытылмас еллар» (1949 – 1966), Ш. Усмановның «Легион юлы» (1921 – 1935) һ.б.), әмма берьяклы, социалистик реализм таләп иткәнчә генә каралды. Ф. Сафин әсәрендә «теге»ләре дә, болары да көч кулланучылар буларак бирелә: яшьләрне көчләп үз армияләренә алалар, гади халыкның мал-мөлкәтен, сугышка яраклы атларын, кирәк-ярагын талыйлар, каршы килүчеләр булса, аталар. Гражданнар сугышы елларында таркау гаскәрләрнең кылган гамәлләре, кызылларның мәрхәмәтсез, ерткыч булулары, җитәкче большевикларның һәртөрле башбаштаклыкларга юл куюлары, кеше шәхесе белән санлашмаулары тормышчан вакыйгаларда сурәтләнә, илнең коточкыч, бернинди логика кысаларына да сыймаган хәлләргә дучар ителүе күпсанлы конкрет мисаллар белән раслана.

Ф. Сафин беренче китап дәвамында геройның характер үсешен, шул тарихи шартларда ялкынлы революционер булып җитлегүен

эзлекле рәвештә сурәтләп бара. Дәүләтъяров үз чорының төрле иҗтимагый катлаулары белән якыннан кызыксынып һәм алар белән тыгыз бәйләнештә яшәгән хәлдә тасвирлана. Алгы планда милли зыялылар тормышы тора, алар – яшәү мәгънәсен милләткә хезмәт итүдә тапкан, көч-энергияләрен, теләк-омтылышларын яңа социалистик тормыш төзүгә багышлаган кешеләр, күпчелеге тарихи шәхесләр (Ә. Дәүләтъяров, М. Җәлил, Һ. Такташ, Ш. Усманов, Ш. Камал һ.б.). Яңа хөр, гадел дәүләт төзү идеясе милли зыялыларның гаменә, изге максатына әйләнә. Бу кешеләрне бер сыйфат – инкыйлаб эшенә бирелгәнлек, социалистик идея, социалистик җәмгыять төзү өчен көрәш берләштерә.

«Өермә» дигән икенче китап 1930–1937 елларны колачлый. Биредә үзәк геройның Урта Азиядәге эшчәнлеге, коллективлаштыру, дин мәсьәләләре үзәккә куела. Авыл хуҗалыгын күмәкләштерү турындагы карарлар нигезендә күп хикмәтләр эшләнә. Яңа җәмгыятьнең, үз тәртипләрен урнаштырганда, аерым сыйнфый төркемнәргә һәм шәхесләргә китергән бәла-казалары, кечкенә генә үз милеге, үз хуҗалыгы булган крестьянның каршы торып маташуы авыр кичерешләр белән күз алдына бастырыла. Әсәрдә дини мәсьәләләр дә күтәрелә. Совет җәмгыяте дингә, гасырлардан килгән гореф-гадәтләргә каршы көрәш башлый һәм аны гайре табигый ысуллар белән тормышка ашыра. Совет кануннарының мәгънәсезлеге, дөрес булмавы Г. Дәүләтъяров теле белән әйтелә: *«...халыкның аңына шушы алласыз динне сеңдерәләр. Бутала халык, кыйбласын югалта»* [Сафин, 2003, б. 103]. Бүлекнең башында бирелгән табигать сурәте дә аллегорик мәгънәгә ия: *«Чулман өсләп сыек рәшә сыман томан күтәрелә. Яңа ел башына кадәр ишле карлар явып, көннәр буранлап торды да, кинәт җылытып, җепшетеп җибәрде. Атна чамасы шулай булды. Карлар чып-чынлап эри башлады дигәндә генә, кыш яңадан бар ихтыярын, бар гайрәтен үз кулына алды, сансызланып маташкан идегез, менә күрегез инде, алайса, дигәндәй, янә буран котырды, аннан чатнама суыклар башланды»* [Сафин, 2003, б. 202]. Автор биредә илдәге күренеш-хәлләрне, вакыйгаларны предмет-сурәтләр белән атый. Салкын гыйнвар иртәсе илдәге сәясәтне чагылдыра.

Өченче китапта («Ялган тәрәзәле йорт») 1937 – 1938 еллар фаҗигасы – репрессияләр чоры тергезелә. Ф. Сафинның үз геройлары итеп реаль шәхесләрне сайлавы очраклы түгел. Биредә репрессияләрнең кешегә, халыкка күпме кайгы-хәсрәт китерүе аерым кешеләр тормышы аша бирелә. Кеше язмышы халык, милләт, ил язмышы буларак карала. Язучы, чорның реаль картинасын тудырып, коммунистик җәмгыятьнең антиутопик асылын, шәхескә йогынтысын тулы күрсәтә.

Илдә коточкыч сәясәт хөкем сөрә: кешегә нахак бәла тагыла, гаепсезләрдән «халык дошманы» ясала. Казан, башка өлкәләр белән чагыштырганда, халык дошманнары мыжлап торган, милләтчепантөркичел оешмалар киң канат җәйгән өлкә дип табыла, сәяси

көрәш кискенләшә, татар егетләре үтерелә тора. Кеше гомеренә куелган бәя бик арзан. Әлеге фикер чорга хас рәхимсезлекләрне күз алдына бастырган күренешләр, беренче чиратта, күпләгән репрессияләнгәннәр язмышы аша тасвирлана.

Совет чорының асылын күрсәтүдә тарихи шәхес – Әхмәтсафа Дәүләтъяровның тоткан урыны бәхәссез. Дәүләтъяров, нигездә, ике аспектта бирелә: герой – милләт улы, герой – җәмгыятьнең бер вәкиле. Шуларга бәйле рәвештә аның характерында көч, фаҗигалылык, милли сыйфатлар үрелеп бара. Әхмәтсафа – заманча белемле, укымышлы, тырыш, эшчән, намуслы, аек акыллы, гадел, кешелекле, алга омтылучан, туктаусыз үсә, камилләшә торган кеше, шул чордагы татар чынбарлыгының төрле өлкәләре белән якыннан кызыксынып яшәүче, дөньяга киң карашлы шәхес. Ул республиканың беренче кешеләреннән: иң элек Минзәләдә МТС политбүлеге урынбасары, аннары «Кызыл Татарстан» газетасының баш редакторы, соңрак Таткнигоиздат партия оешмасында җитәкче, 1937 елның июненнән өлкә комитеты әгъзасы, 1937 елның сентябреннән Татарстан Республикасы Халык Комиссарлары Советы рәисе. Әхмәтсафа илдәге хәлләргә битараф кала алмый, ул – аның актив катнашучысы. Совет системасының шәхесне изүчән сәясәте Әхмәтсафаны туры юлдан яздыра, ул большевиклар кулында югалып кала, алданып, иске тормыш күренеше булып тоелган диненнән, мәдрәсәләреннән баш тарта. Хакимият егеткә үзен кызганмыйча эшләү өчен шартлар тудырып, гамәлләрен хуплап, асылда, аны коллыкка төшерә. Әсәрдә революциягә, социалистик киләчәккә ышанучылар һәм аның корбаннары булган кешеләргә карата «тере курчак» оксюмороны кулланыла: Әхмәтсафа ишегалдында нәни кызчыкның җансыз курчакны сөйрәп баруын күрә, аның язмышы да җансыз курчакныкына тиң: *«Курчак язмышы... Үз язмышын оештырудан мәхрүмлек... Сискәнеп китте: чынлыкта ул үзе дә кайбер кешеләр кулында курчак кына бит...»* [Сафин, 2003, б. 412]. 1937 елда Дәүләтъяров Сталин репрессияләренең корбаны була: кулга алына, вәхшиләрчә җәзалана һәм 1938 елның 9 маенда «халык дошманы» буларак атып үтерелә.

Геройның трагик язмышы язучы тарафыннан татар милләтенең фаҗигасы итеп карала. Геройның фаҗигасы – аның якты киләчәккә, социалистик идеяләргә, большевикларга сукырларча ышануында, халыкның якты киләчәге өчен көрәшнең асылын дөрес аңламавында, чынбарлыкны үзгәртергә көче җитмәвендә. Бу хәл совет чорында кешенең хокуксызлыгына, җәмгыять колы, корбаны булуына барып тоташа.

Романда тәнкыйди һәм фәлсәфи башлангыч көчле. Фәлсәфи фикерләрне калкыту өчен, язучы еш кына татар шигъри мирасына мөрәҗәгать итә. Әсәр тукымасында Дәрдемәнд шигырьләреннән, «Идегәй»дән өзекләр китерелә. Текст укучыны «Идегәй» сюжетына алып китә һәм тарихи вакыйгаларны искә төшерә. Уңышлы кулланылган аллюзия алымы Алтын Урда вакытында да, революция чо-

рында да кеше язмышларының хакимият өчен көрәш тәгәрмәче астында тапталуын искәртә, теләсә кайсы заманда хакимият өчен сугыш бара һәм ул илләр, шәхесләр тормышын тамырдан үзгәртә, үзенә буйсындыра, дигән фикергә китерә [Заһидуллина, 2006, б. 74].

Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» роман-трилогиясендә XX гасырны тетрәткән үзгәрешләр – социалистик җәмгыять урнашу ике яклы: кешелек тарихының бер сәхифәсе буларак һәм милли тарихның бер буыны итеп яктыртыла, әлеге системада шәхеснең тоткан урыны, башкарган роле төгәл билгеләнә: ул – корбан, кол. Әсәрнең әлеге үзенчәлеген ассызыклап, Р. Мостафин болай дип яза: «Ф. Сафинның «Саташып аткан таң» романы татар халкының совет чоры тарихын тулы чагылдыра. Минем карашка, соңгы елларда басылган әсәрләр арасында әлеге роман – иң әһәмиятлесе һәм җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итәргә лаеклысы» [Мустафин, 2004].

Язучының «Шәүлә» (2003–2005) романында ретроспекция алымы нигезендә совет чоры, шәхес культының гаиләләргә, балаларга алып килгән фаҗигасы бүгенге көн күзлегеннән чыгып бәяләнә. Биредә совет чорына «сәяхәт» ясала. Хатлар, хатирәләр, әңгәмәләр, истәлекләр бирү, әсәр тукымасына беркетмәләр, документлар кертеп җибәрү кебек алымнарны файдалану язучыга чор картинасын тулы тергезергә ярдәм итә.

Хатларда совет чоры атмосферасы саклана. Рабига Сарымсакованың Темлагтан килгән хатларында, шәхси хис-кичерешләре, теләк-омтылышлары, уйланулары белән беррәттән, дөньяви мәсьәләләр, тормышчан дөреслек тә чагыла, совет чорының хатын-кызларга, аналарга китергән кайгы-хәсрәте бөтен тулылыгында күз алдына бастырыла. Геройларның хатирәләре, совет чоры, Рабига Сарымсакова хакындагы истәлекләре узгандагы хәвефле дәверләргә гаепсезгә лагерьларда, төрмәләрдә булып кайткан кешеләр күзе белән карарга мөмкинлек бирә. Мария Ильина, Мәгүзә Фаршатова кебек хатын-кызлар белән әңгәмәләр совет чорының шәхесне рухи изгән, юк иткән сәясәтен тагын бер кат дәлилли.

Беркетмәләр, Идел буе хәрби округы, хәрби трибуналына җибәрелгән гариза үрнәкләрен әсәр тукымасына кертеп җибәрү дә тарихи вакыйгаларны тирәнрәк яктыртырга ярдәм итә, әсәрнең тормышчанлыгын, ышаныч көчен арттыра. Әлеге документлар аның язучы уйдырмасы гына түгеллеген раслый, совет чынбарлыгының асылын ача.

Язучы яратып кулланган ассоциатив янәшәлекләр бу очракта чор үзенчәлекләрен калкуландыру максатында файдаланыла. Машина астына кереп юк булган күгәрчен язмышы Әхмәтсафа, Рабига язмышына тәңгәл. Тынычлык символы булган күгәрчен тулаем ил язмышына да ишарә ясый.

Язучы махсус рәвештә М. Җәлил, Тютчев шигырьләреннән өзекләр (аллюзия) китерә. Совет поезды белән кара елан арасындагы охшашлыкка нигезләнеп, М. Җәлил тарафыннан китерелгән чагыштыру

Ф. Сафин әсәрендә дә яңгыраш таба, символик мәгънә ала. Еланнар әсәрдә «язмышны сагалап торучы куркыныч бер сурәт» буларак берничә мәртәбә очрый: үткәннәргә, тарихка, Рабига тормышына бәйле хатирәләрдә, Явас урманнарына сәяхәт вакытында бу аеруча күзгә ташлана.

Поэтик образ буларак Явас урманы аерым игътибарга лаек. Урман – үткәннәрне бүгенге көн белән бәйләп торучы урын. Еланнар белән тулы сазлыклы урман геройларны еракта калган көннәргә алып кайта, күңелләренә шом, курку сала.

Бүгенгеләрне үткән (совет чоры) белән бәйләп торучы символик образ – Шәүлә. Аллегорик мәгънәгә ия символ әсәрнең исеменә үк чыккан. Шәүлә – совет чорының асылын, үткәннәрдәге хәл-вакыйгаларны белдерә, аларның символына әверелә. Ул совет идеологиясенең асылын да, күзәтү-шикләнүгә корылган сәяси системаны да символлаштыра.

Шәүлә конкрет кеше образлары белән янәшәлектә дә тасвирлана. Заманга, бүгенге көнгә бәйле рәвештә әсәрдә капма-каршы, контраст образлар тудырыла: Язучы һәм Шома. Язучы – гаделлек һәм азатлык-ирек өчен көрәшүче, әхлаклы, туры сүзле. Шома образын тудырганда шартлылык, арттыру алымы катнаша. Шомага хас төп билге-сыйфатлар (бозыклык, алдау, властька омтылу, гадел кешеләрне юк итү һ.б.) әсәр дәвамында төрле ситуация-вакыйгаларда ачылып килә. Язучының Шоманы Шәүлә белән чагыштыруы да юкка түгел: Шоманың үз-үзен тотышы совет чорында кылынган гаделсезлекләргә тәңгәл, образда советчыл системаның шәхесне юк итеп, шәүләгә әйләндерә торган сәясәтенә ишарә бар.

Әсәр ахырында Язучының баскычтан югарыга менеп китүе, Шоманың түбән төшүендә символик мәгънә ята: автор дөреслек-ялган, яхшылык-явызлык бәрелешендә беренчесенең бәхәссез өстенлеген раслый. Әсәрнең төп идеясе: *«Совет чорында һәрнәрсәдән миф ясау гадәткә кергән иде»* [Сафин, 2008, б. 11], дигән сүзләрдә кабатлана. Әдип совет чоры авырлыкларын, гаделсезлекләрен, әлеге чорның кешегә ясаган йогынтысын, ялган, мифка корылган нигезен сәнгатьчә ача, ачыклый һәм дәлилли.

Шул рәвешле, Ф. Сафинның «Соңгы күз», «Гөлҗиһан» повестьлары, «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе, «Шәүлә» романы совет чынбарлыгын тулы бер хәрәкәттәге картина буларак, ил һәм кешеләр язмышында күрсәтүе белән әһәмиятле, бу әсәрләр советчыл мифны җимерүгә, кешеләр аңында советчыл үткәнгә иҗтимагый-сәяси бәяне үзгәртүгә хезмәт итә. Язучы, шул рәвешле, үз әсәрләре белән татар әдәбиятындагы калыплашкан карашлардан арынуга юл ача. Әсәрләрендәге матур тел-сөйләм, һәр сүзгә игътибарлы булу, символлар ярдәмендә эчтәлекне тирәнәйтү, табигать сурәтләре белән эмоциональ тәэсирлелекне арттыру кебек алымнар Ф. Сафинның беркемнекенә дә охшамаган үз стилен хасил итә.

**Әдәбият**

*Әгъләмов М.* Шигъри әнкә баласыдыр... // Шәһри Казан. 1993. 10 июль.

*Заһидуллина Д.* Кызгана белгән игелек кыла // Ватаным Татарстан. 2002. № 154.

*Заһидуллина Д.* Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). Казан: Мәгариф, 2006. 56 б.

*Мустафин Р.* Ступени ведут и вверх и вниз // Республика Татарстан. 2004. № 154.

*Хөснетдинова Л.* Таңнар саташып атмый // Мәйдан. 2004. № 1. 22 б.

*Сафин Ф*. Саташып аткан таң: Роман-трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

*Сафин Ф.* Соңгы күз: повесть, хикәяләр. Чаллы: КамАЗ, 1992.

*Сафин Ф.М.* Шәүлә: роман, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.

*Мәкалә «2014–2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасының 3.5.4 санлы чарасы кысаларында нәшер ителә*

***Ситдыйкова Чулпан Фәрит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, «Language+» телләр өйрәнү студиясе мөгаллиме*